**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 5 июнь № 415

г. Казань

2014 елда «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру барышы һәм 2015 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендәге дәүләт сәясәтен алга таба гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «2014 елда «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру барышы һәм 2015 елга бурычлар турында» хисабын хупларга.

2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклаучы технологияләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе һәм Татарстан Республикасының Социаль-икътисади мониторинг комитеты белән берлектә, 2015 елның 1 июленә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү программаларын үтәү буенча мәгълүмати-аналитик хисаплар әзерләү өчен төбәк статистика күзәтчелеге формаларын камилләштерү турында тәкъдимнәр кертергә.

3. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклаучы технологияләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе һәм Татарстан Республикасының мәнфәгатьле министрлыклары һәм ведомстволары белән берлектә:

2015 елның 1 июленә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга еллык республика конкурсын үткәрү кысаларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмаларының энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендәге эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү методикасы турында тәкъдимнәр кертергә;

2015 ел дәвамында Татарстан Республикасы бюджет тармагындагы җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә квалификацияләрен күтәрү курслары буенча укытуны оештыруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына квартал саен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре яктылыгында күпфатирлы торак фондының энергия ресурслары нәтиҗәлелегенә анализ үткәрергә һәм аның нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырырга.

5. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына квартал саен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре яктылыгында бюджет тармагының энергия ресурслары нәтиҗәлелегенә анализ үткәрергә һәм аның нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырырга.

6. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә, 2015 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасында энергия нәтиҗәлелеген күтәрү белән идарә итүнең төбәк мәгълүмат системасын модернизацияләү һәм үстерү хакында тәкъдимнәр кертергә.

7. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына 2015 ел дәвамында Татарстан Республикасы оешмалары һәм учреждениеләрендә гамәлгә ашырыла торган энергия саклау өлкәсендәге чаралар һәм проектларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту юлы белән энергия саклауны һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрүне пропагандалау буенча эш үткәрергә.

8. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә муниципаль программаларга энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү буенча максатчан күрсәткечләрне (индикаторларны) һәм чараларны актуальләштерү өлешендә федераль законнар таләпләре нигезендә төзәтмәләр кертүне үткәрергә һәм аларны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бердәм рәсми порталында урнаштыруны тәэмин итәргә;

квартал саен Татарстан Республикасының энергия нәтиҗәлелеген күтәрү белән идарә итүнең төбәк мәгълүмат системасына энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә билгеләнгән хисаплылык формалары һәм индикаторлар буенча мәгълүмат тапшыруны тәэмин итәргә.

9. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры Р.Х.Зариповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\415.docx